Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге составына керүче Таш-Кичу авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«14» апрель 2024 ел № 11/3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены

КАРАР БИРДЕ:

1. Үзгәрешләр кертергә:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге составына керүче Таш-Кичу авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл еслегенең юл өлеше астына су үткәрү торбасын елешчә алмаштыру һәм куаклардан, агачлардан чистарту (махсус техника));

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Таш-Кичу авылында урамнарны яктыртуны ремонтлау ечен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) сатып алу)».

2) 1 пунктның икенче-еченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 27 октябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Таш-Кичу авылында гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юл өслегенең юл өлеше астына су үткәрү торбасын елешчә алмаштыру һәм куаклардан, агачлардан чистарту (махсус техника));

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (Таш-Кичу авылында урамнарны яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) сатып алу)».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү ечен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Мусабай-Завод авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Мусабай-Завод авыл җирлеге Башлыгы З.З. Хөсәинова